# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Күмәк хезмәт бәхәсләрен хәл итү тәртибе хакында

### I бүлек
### Гомуми нигезләмәләр

1 статья. Әлеге Законның бурычлары һәм гамәли даирәсе

Әлеге Закон күмәк хезмәт бәхәсләрен хәл итүнең хокукый нигезләрен, тәртибен һәм алымнарын, шулай ук күмәк хезмәт бәхәсләрен хәл итү барышында Татарстан Республикасында эш ташлауга хокукны гамәлгә ашыруның тәртибен билгели.

Эшләүчеләрнең индивидуаль хезмәт хокукларын күмәк яклауга бәйле рәвештә барлыкка килгән күмәк хезмәт бәхәсләрен хәл итү әлеге Закон предметы булып тормый.

Бу Законда билгеләнгән нормалар барлык эшләүчеләргә, эш бирүчеләргә, шулай ук эшләүчеләрнең һәм эш бирүчеләрнең берләшмәләренә, аларның вәкаләтле органнарына кагыла.

Конституциячел төзелешне, башка затларның әхлагын, сәламәтлеген, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, дәүләт иминлеген тәэмин итү максатларында кирәк булган дәрәҗәдә, Закон белән күмәк хезмәт бәхәсләрен хәл итүнең һәм эш ташлау хокукын гамәлгә ашыруны чикләүнең башка тәртибе дә урнаштырылырга мөмкин.

Әлеге Закон эшләүчеләрнең, эш бирүчеләрнең, шулай ук эшләүчеләрнең һәм эш бирүчеләрнең берләшмәләре, аларның вәкаләтле органнарының "Күмәк хезмәт бәхәсләрен хәл итү тәртибе ту-

рында" Федераль закон билгеләгән тәртиптә күмәк хезмәт бәхәсләрен хәл итү хокукын чикләми.

2 статья. Бу Законда кулланыла торган төп төшенчәләр

Күмәк хезмәт бәхәсе - эшләүчеләр белән эш бирүчеләр (алга таба - яклар) арасында хезмәт шартларын билгеләү һәм үзгәртү (эш хакын да кертеп), социаль-хезмәт мөнәсәбәтләре мәсьәләләре турында күмәк шартнамәләр һәм килешүләрне төзү, үзгәртү һәм үтәү буенча көйләнеп бетмәгән фикер каршылыклары.

Килештерү процедуралары - күмәк хезмәт бәхәсләрен, аларны килештерү комиссиясе тарафыннан хәл итү максатында, арадашчы катнашында якларның хезмәт арбитражында каравы.

Эшләүчеләрнең вәкилләре - һөнәр берлекләренең һәм аларның берләшмәләренең үз уставлары нигезендә вәкиллеккә вәкаләт бирелгән органнары яисә хезмәткәрләрнең үзләренең оешма, филиал, вәкиллек җыелышы (конференциясе) тарафыннан сайланган һәм вәкаләт бирелгән башка вәкилләре.

Эш бирүчеләрнең вәкилләре - оешмаларның җитәкчеләре яки оешма уставы һәм башка хокукый актлар нигезендә бүтән вәкаләтле затлар, эш бирүчеләр берләшмәләренең вәкаләтле органнары яисә эш бирүчеләр тарафыннан вәкаләткә ия башка органнар.

Күмәк хезмәт бәхәсенең башлану мизгеле - эш бирүченең эшләүчеләр таләпләренең барысын да яки өлешчә кире кагуы турындагы карарын хәбәр иткән көн яисә эш бирүченең үз карары хакында эшләүчеләр вәкиленә әлеге Законның 4 нче статьясында билгеләнгән вакытларда хәбәр итмәве.

Эш ташлау - эшләүчеләрнең күмәк хезмәт бәхәсен хәл итү максатында хезмәт вазыйфаларын (тулысынча яки өлешчә) башкарудан вакытлыча ихтыярый баш тартуы.

П бүлек

Күмәк хезмәт бәхәсен хәл итү тәртибе

3 статья. Эшләүчеләр таләпләренең куелуы

Эшләүчеләр һәм аларның вәкилләре таләпләр кую хокукына ия.

Оешма, филиал, вәкиллек хезмәткәрләренең таләпләре эшләүчеләрнең җыелышында (конференциясендә) күпчелек тавыш белән чыгарыла. Шунда ук күмәк хезмәт бәхәсен хәл итүдә катнашу әчен вәкаләтле вәкилләр сайлана. Эшләүчеләрнең төрле вәкилләре тарафыннан бер үк төрле таләпләр куелган очракта, әлеге күмәк хезмәт бәхәсен хәл итүдә катнашу өчен уртак орган төзелергә мөмкин.

Эшләүчеләрнең вәкилләре таләпләрне устав яисә вәкаләтле органны төзегән хезмәткәрләрнең җыелышы (конференциясе) карары билгеләгән тәртиптә куялар.

Эш бирүче хезмәткәрләргә яки аларның вәкилләренә таләпләрне кую җыелышы (конференциясе) уздыру өчен кирәкле бина бирергә тиеш һәм аны үткәрүгә комачаулык итәргә хаклы түгел.

Таләпләр язма рәвештә бәян ителә һәм эш бирүчегә җибәрелә.

Язма рәвештәге таләпләрнең күчермәсе Күмәк хезмәт бәхәсләрен җайга салу буенча республика хезмәтенә җибәрелә, ул орган таләпләрнең икенче як тарафыннан да алынуын тикшерергә тиеш.

<u>4 статья.</u> Эшләүчеләрнең таләпләрен карау

Эш бирүче эшләүчеләрнең үзенә юлланган таләпләрен карауга кабул итәргә һәм үзенең карары турында эшләүчеләрнең вәкиленә, таләпләрне алганнан соң өч эш көне эчендә, язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

<u>5 статья.</u> Килештерү процедуралары

Күмәк хезмәт бәхәсен хәл итү тәртибе түбәндәге этаплардан тора: күмәк хезмәт бәхәсен килештерү комиссиясендә карау, күмәк хезмәт бәхәсен арадашчы катнашында һәм (яисә) хезмәт арбитражында карау.

Күмәк хезмәт бәхәсен килештерү комиссиясендә карау мәҗбүри этап булып тора. Килештерү комиссиясендә килешүгә ирешелмәгәндә, күмәк хезмәт бәхәсендәге яклар аны арадашчы катнашында яисә хезмәт арбитражында карауга керешәләр.

Күмәк хезмәт бәхәсен хәл итү барышында эшләүчеләр үз та-

ләпләрен яклап, законнар нигезендә җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, пикетлар үздырырга хокуклы.

Күмәк хезмәт бәхәсендә катнашучы якларның берсе дә килештерү процедураларында катнашудан читләшергә тиеш түгел.

Якларның вәкилләре, килештерү комиссиясе, арадашчы, хезмәт арбитражы, Күмәк хезмәт бәхәсләрен җайга салу буенча республика хезмәте килеп туган күмәк хезмәт бәхәсен хәл итү өчен законнарда каралган барлык мөмкинлекләрдән дә файдаланырга тиеш.

Килештерү процедуралары әлеге Законның 6-8 нче статьяларында каралган вакытларда уздырыла. Кирәк булган очракта килештерү процедураларын үткәрү вакыты, күмәк хезмәт бәхәсендәге яклар белән килешенеп, озайтыла да ала.

<u>6 статья.</u> Күмәк хезмәт бәхәсенең килештерү комиссиясе тарафыннан каралуы

Килештерү комиссиясе, күмәк хезмәт бәхәсе башлау мизгеленнән өч эш көненә кадәр вакыт эчендә, тигез хокуклылык нигезендә, яклар вәкилләреннән төзелә, эш бирүченең тиешле боерыгы һәм эшләүчеләр вәкиленең карары (беркетмәсе) белән рәсмиләштерелә.

Эш бирүче килештерү комиссиясенә эшләү өчен бина бирә һәм кирәкле шартларны булдыра.

Күмәк хезмәт бәхәсе килештерү комиссиясе тарафыннан ул төзелгәннән соң биш эш көне эчендә каралырга тиеш.

Килештерү комиссиясенең карары якларның килешүе белән кабул ителә, беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул яклар өчен мәҗбүри көчкә ия һәм карарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта үтәлә.

Килештерү комиссиясендә килешүгә ирешелмәгәндә, яклар килештерү процедураларын арадашчы катнашында яисә хезмәт арбитражында карауны дәвам итәләр.

Күмәк хезмәт бәхәсен килештерү комиссиясе караганнан соң килештерү процедураларын куллану буенча уртак фикергә киленмәсә, яклар хезмәт арбитражы төзүгә керешергә тиешләр.

7 статья. Күмәк хезмәт бәхәсен арадашчы катнашында карау

Күмәк хезмәт бәхәсен тикшерү өчен якларның килешүе буенча Күмәк хезмәт бәхәсләрен җайга салу буенча республика хезмәтенә бәйсез рәвештә яки аның тәкъдиме белән арадашчы чакырыла ала.

Әгәр килештерү комиссиясендә килешүгә ирешә алмаганнан соң өч эш көненә кадәр яклар арадашчы кандидатурасы хакында уртак фикергә килә алмасалар, ул Күмәк хезмәт бәхәсләрен җайга салу буенча республика хезмәте тарафыннан билгеләнә.

Күмәк хезмәт бәхәсен арадашчы катнашында карау тәртибен, күмәк хезмәт бәхәсе яклары белән килешеп, арадашчы билгели.

Арадашчы эш бирүчедән күмәк хезмәт бәхәсенә кагылышлы тиешле документларны һәм белешмәләрне соратып алырга хокуклы.

Күмәк хезмәт бәхәсен арадашчы катнашында карау, аны чакырганнан (билгеләгәннән) соң җиде календарь көн эчендә башкарыла һәм язма рәвештә килештерелгән карар кабул итү яисә каршылыклар беркетмәсе төзү белән тәгәлләнә.

8 статья. Күмәк хезмәт бәхәсен хезмәт арбитражында карау

Хезмәт арбитражы күмәк хезмәт бәхәсенең яклары һәм Күмәк хезмәт бәхәсләрен җайга салу буенча республика хезмәте тарафыннан күмәк хезмәт бәхәсен килешерү комиссиясе яисә арадашчы караганнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча төзелүче, күмәк хезмәт бәхәсен карау буенча вакытлыча эш итүче орган булып тора.

Хезмәт арбитражы якларның килешүе буенча хезмәт арбитрлары арасыннан Күмәк хезмәт бәхәсләрен җайга салу буенча республика хезмәте яки күмәк хезмәт бәхәсе яклары тәкъдим иткән өч кеше составында төзелә.

Хезмәт арбитражы составына күмәк хезмәт бәхәсе яклары вәкилләре керә алмый.

Хезмәт арбитражын төзү, аның составы, регламенты, вәкаләтләре эш бирүченең, эшләүчеләр вәкиленең һәм Күмәк хезмәт бәхәсләрен җайга салу буенча республика хезмәтенең уртак карары белән рәсмиләштерелә.

Эш бирүче хезмәт арбитражына бина бирә һәм эшләү өчен тиешле шартлар тудыра.

Кумәк хезмәт бәхәсе якларның вәкилләре катнашында хезмәт арбитражы төзелгәннән соң биш эш көне эчендә карала.

Хезмәт арбитражы:

- якларның мөрәҗәгатьләрен карый;
- кумәк хезмәт бәхәсен карау өчен кирәкле документлар һәм белешмәләр ала;
- кирәк очракта дәүләт хакимияте һәм идарәсенең республика һәм җирле органнарына, җирле үзидарә органнарына кумәк хезмәт бәхәсе аркасында ихтимал булган социаль нәтиҗәләр турында хәбәр итә;
- кумәк хезмәт бәхәсенең асылы буенча тәкъдимнәр эшли.

Кумәк хезмәт бәхәсен җайга салу буенча хезмәт арбитражы тәкъдимнәре якларга язма рәвештә тапшырыла һәм ул, әгәр яклар аны үтәү турында язма рәвештә килешү төзегән булсалар, яклар өчен мәҗбүри була.

<u>9 статья.</u> Кумәк хезмәт бәхәсен хәл итүгә бәйле рәвештә эшләүчеләрнең гарантияләре

Килештерү комиссиясе әгъзалары, арадашчылар, хезмәт арбитрлары кумәк хезмәт бәхәсен хәл итүдә катнашканда бер ел дәвамында өч айдан да артык булмаган чорга, уртача хезмәт хакы сакланып, төп эшләреннән азат ителәләр.

Килештерү комиссиясе әгъзалары, арадашчылар һәм хезмәт арбитрлары хезмәтенә түләү кумәк хезмәт бәхәсендә катнашучы эш бирүче исәбеннән башкарыла.

Кумәк хезмәт бәхәсен хәл итүдә катнашучы һөнәр берлекләре вәкилләре, аларның уставлары нигезендә вәкиллеккә вәкаләт алган берләшмәләре яки оешма, филиал, вәкиллек хезмәткәрләренең җыелышы (конференциясе) тарафыннан сайланган һәм вәкаләт бирелгән үз вәкилләре кумәк хезмәт бәхәсен хәл итү чорында дисциплинар җәзага тартыла алмый, вәкиллеккә вәкаләт биргән орган ризалыгыннан башка, администрация инициативасы белән башка эшкә күчерелми, эштән азат ителә алмый.

<u>10 статья.</u> Эш бирүченең килештерү процедураларыннан читләшүе

Эш бирүче килештерү комиссиясен оештырудан һәм аның эшен-

нән читләшкән очракларда күмәк хезмәт бәхәсе хезмәт арбитражы каравына тапшырыла.

Эш бирүче хезмәт арбитражын төзүдән, күмәк хезмәт бәхәсен хезмәт арбитражында караудан, шулай ук аның тәкъдимнәрен үтәүдән читләшкән очракларда, әгәр аларны үтәү мәҗбүрилеге турында килешүгә ирешелгән булса, эшләүчеләр эш ташлауга керешә алалар.

11 статья. Күмәк хезмәт бәхәсләрен җайга салу буенча республика хезмәте

Күмәк хезмәт бәхәсләрен җайга салу буенча республика хезмәте - килештерү процедурасы оештыру һәм аларда катнашу юлы белән күмәк хезмәт бәхәсләрен хәл итүгә булышлык итүче дәүләт органы.

Күмәк хезмәт бәхәсләрен җайга салу буенча республика хезмәте түбәндәгеләрне башкара:

- күмәк хезмәт бәхәсләрен хәбәр итеп, теркәүне башкара;
- кирәк очракта күмәк хезмәт бәхәсләре яклары вәкилләренең вәкаләтләрен тикшерә;
- арадашчылар һәм хезмәт арбитрлары исемлеген булдыра;
- күмәк хезмәт бәхәсләрен хәл итү өчен махсус арадашчылар һәм хезмәт арбитрлары әзерли;
- күмәк хезмәт бәхәсләренең килеп чыгу сәбәпләрен һәм шартларын ачыклый һәм гомумиләштерә, аларны бетерү өчен тәкъдимнәр әзерли;
- күмәк хезмәт бәхәсләрен хәл итүнең барлык этапларында якларга ысулый ярдәм күрсәтә;
- эшләүчеләр һәм эш бирүчеләрнең вәкилләре, дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары белән бергә күмәк хезмәт бәхәсләрен җайга салу эшен оештыра.

Күмәк хезмәт бәхәсләрен җайга салу буенча республика хезмәте вазыйфаларын әлеге Закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслаган Нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасының Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт комитеты башкара.

Күмәк хезмәт бәхәсләрен җайга салу буенча республика хезмәте хезмәткәрләре, тиешле үрнәктәге таныклыкны күрсәтеп, кү-

мәк хезмәт бәхәсләрен җайга салу максатларында, әлеге бәхәсләрне тудыра торган сәбәпләрне ачыклау һәм бетерү өчен, оешмаларга, аларның филиалларына, вәкиллекләренә тоткарлыксыз керү хокукыннан файдаланалар.

12 статья. Күмәк хезмәт бәхәсләрен хәл итү барышында килешү

Күмәк хезмәт бәхәсен хәл итү барышында яклар арасында ирешелгән килешү язма рәвештә рәсмиләштерелә һәм яклар өчен мәҗбүри көчкә ия була. Аны үтәүнең барышын күмәк хезмәт бәхәсендәге яклар тикшереп тора.

Ш бүлек

Эш ташлауга хокукны гамәлгә ашыру

13 статья. Эш ташлауга хокук

Әгәр килештерү процедуралары күмәк хезмәт бәхәсен хәл итүгә китермәсә яки эш бирүче килештерү процедураларыннан читләшергә тырышса, күмәк хезмәт бәхәсен хәл итү барышында ирешелгән килешүне үтәмәсә, эшләүчеләр, эш ташлау хокукын да кертеп, җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр һәм пикетлар оештырудан файдаланырга хокуклы.

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә эшләүчеләр, күмәк хезмәт бәхәсен хәл итүнең иң чик чарасы буларак, эш ташлау хокукына ия.

Эш ташлауда катнашу ихтыярый. Һичкем анда катнашырга яки катнашудан баш тартырга мәҗбүр ителә алмый.

Эшләүчеләрне эш ташлауда катнашырга яки анда катнашудан баш тартырга мәҗбүр итүче затлар законнарда билгеләнгән тәртиптә җаваплы булалар.

Эш бирүче вәкилләре эш ташлауны оештырырга һәм анда катнашырга хокуклы түгел.

14 статья. Эш ташлауны игълан итү

Эш ташлауны игълан итү карары оешма, аның филиалы, вәкил-

леге яисә һөнәр берлекләре оешмасы, һөнәр берлекләре берләшмәсе җыелышы (конференциясе) тарафыннан кабул ителә.

Әгәр җыелышта хезмәткәрләрнең, һөнәр берлекләре оешмасы әгъзаларының (конференция делегатларының) гомуми саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, хезмәткәрләрнең һөнәр берлекләре оешмасы җыелышы (конференциясе) хокукый көчкә ия була.

Җыелышта (конференциядә) катнашучыларның кимендә яртысы яклап тавыш биргәндә, карар кабул ителгән дип санала.

Килештерү комиссиясе биш календарь көн эшләгәнән соң, бер тапкыр бер сәгатьлек кисәтүле эш ташлау игълан итәргә мөмкин, бу хакта эш бирүчегә өч эш көненнән дә соңга калмыйча язма рәвештә хәбәр ителергә тиеш.

Кисәтүле эш ташлау вакытында аңа җитәкчелек итүче орган әлеге Закондагы 16 нчы статьяның 3 һәм 4 өлешләре нигезендә кирәкле эшләрнең (хезмәт күрсәтүләрнең) минимумын тәэмин итә.

Эш ташлауга җитәкчелек итүче орган эш бирүчегә эш ташлауның башлануы хакында кимендә 10 календарь көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

Эш ташлауны игълан итү турындагы карарда түбәндәгеләр күрсәтелә:

- яклар арасында эш ташлауны оештыруга һәм үткәрүгә сәбәп булып торган каршылыклар исемлеге;
- эш ташлау башлануның көне һәм вакыты, аның дәвамлылыгы һәм катнашучыларның күздә тотылган саны;
- эш ташлауга җитәкчелек итүче орган, эшләүчеләрнең килештерү процедураларында катнашуга вәкаләт бирелгән вәкилләре составы;
- эш ташлауны үткәрү вакытында оешмада, аның филиалында, вәкиллегендә кирәкле эшләр (хезмәт күрсәтүләр) минимумы буенча тәкъдимнәр.

Эш бирүче алда торган эш ташлау турында Күмәк хезмәт бәхәсләрен җайга салу буенча республика хезмәтен кисәтә.

<u>15 статья.</u> Эш ташлауга җитәкчелек итүче орган

Эш ташлауга эшләүчеләрнең җыелышы (конференциясе) сайлаган орган яки һөнәр берлекләренең тиешле органы җитәкчелек итә.

Эш ташлауга җитәкчелек итүче орган хезмәткәрләрнең җыелышын (конференциясен) җыярга, эшләүчеләр мәнфәгатьләренә кагыла торган мәсьәләләр буенча эш бирүчедән мәгълүмат алырга, бәхәсле мәсьәләләр буенча бәяләмәләр әзерләү өчен белгечләр җәлеп итәргә хаклы.

Эш ташлауга җитәкчелек итүче орган эш ташлауны туктатып торырга хокуклы. Эш ташлауны яңадан башлау өчен бәхәснең килештерү комиссиясе, арадашчы яки хезмәт арбитражы тарафыннан кабат каралуы таләп ителми. Эш бирүче һәм Күмәк хезмәт бәхәсләрен җайга салу буенча республика хезмәте эш ташлауны яңадан дәвам итү турында кимендә өч эш көне алдан кисәтелергә тиеш.

Күмәк хезмәт бәхәсен җайга салу хакындагы килешүгә яклар тарафыннан кул куелган очракта яисә эш ташлау законсыз дип табылганда, әгәр җыелыш (конференция) карарында башкасы күздә тотылмаган булса, эшләүчеләрнең җыелышы (конференциясе) тарафыннан эш ташлауга җитәкчелек итү өчен сайлаган органның вәкаләтләре туктатыла.

16 статья. Эш ташлау барышында якларның бурычлары

Эш ташлауны үткәрү вакытында яклар килештерү процедураларын үткәрү юлы белән күмәк хезмәт бәхәсен хәл итүне дәвам итәргә тиеш.

Эш бирүче, дәүләт хакимияте һәм идарәсенең тиешле органнары, җирле үзидарә органнары һәм эш ташлауга җитәкчелек итүче орган эш ташлау чорында җәмәгать тәртибен саклау, оешманың, аның филиалының, вәкиллегенең һәм физик затларның мөлкәте саклануны, шулай ук эшләүдән туктатылган очракта кешеләр гомеренә һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч тудыру ихтималы булган машиналарның, механизмнарның һәм җиһазларның эшләвен тәэмин итү өчен үзләреннән торган барлык чараларны күрергә тиеш.

Эшләре җәмгыятьнең яшәеш өчен мөһим мәнфәгатьләренә бәйле оешмаларда, аларның филиалларында, вәкиллекләрендә эш ташлауны үткәрү вакытында эш ташлауга җитәкчелек итүче орган, эш бирүче белән берлектә кирәкле эшләр (хезмәт күрсәтүләр) минимумын тәэмин итәргә тиеш.

Кирәкле эшләр (хезмәт күрсәтүләр) минимумы дәүләт идарәсенең тиешле органы яки җирле үзидарә органы белән берлектә,

эш ташлауны игълан итү турында карар кабул ителгәннән соң биш көн эчендә якларның килешүе белән билгеләнә.

Килешүгә ирешелмәгән очракта кирәкле эшләр (хезмәт күрсәтүләр) минимумын дәүләт хакимияте һәм идарәсенең тиешле органы яисә җирле үзидарә органы билгели.

Кирәкле эшләр (хезмәт күрсәтүләр) минимумы тәэмин ителмәгән очракта эш ташлау законсыз дип табылырга мөмкин.

17 статья. Законсыз эш ташлаулар

Күмәк хезмәт бәхәсе булганда, әгәр ул кешеләр гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудырса, эш ташлау закон белән тыелган хезмәткәрләр тарафыннан игълан ителсә, шулай ук әлеге Законның 3-8 нче, 12-16 нчы статьяларында каралган вакытларны, процедураларны һәм таләпләрне исәпкә алмыйча игълан ителсә, эш ташлаулар законсыз дип санала.

Эш ташлауга хокук закон нигезендә чикләнә ала.

Эш ташлауны законсыз дип табу турындагы карар эш бирүче гаризасы нигезендә Татарстан Республикасының Югары суды тарафыннан кабул ителә.

Эш ташлауга җитәкчелек итүче орган, суд карары турында эш ташлауда катнашучыларга кичекмәстән хәбәр итәргә тиеш.

Эш ташлауны законсыз дип таныган суд карары, үз көченә кергәннән соң, кичекмәстән үтәлергә тиеш.

Эш ташлауда катнашкан эшләүчеләр эш ташлауны туктатырга һәм эш ташлауга җитәкчелек итүче органга суд карары күчермәсен тапшырганнан соң икенче көннән дә соңга калмыйча эшкә керешергә тиешләр.

Кешеләрнең гомеренә яисә сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда Татарстан Республикасы Югары суды башланмаган эш ташлауны кичектерергә, ә башланганны - Федераль закон нигезендә суд карары законлы көченә кергәнгә кадәр туктатып торырга хокуклы.

Татарстан Республикасының яисә аның аерым территорияләренең яшәешенә мөһим мәнфәгатьләрен тәэмин итү өчен аеруча әһәмиятле очракларда Татарстан Республикасы Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Югары суды мәсьәләне хәл иткәнчегә кадәр, әмма ун календарь көннән дә соңга калмыйча эш ташлауны туктатып торыр-

га хокуклы.

18 статья. Эш ташлауга бәйле рәвештә эшләүчеләрнең гарантияләре һәм хокукый хәле

Әлеге Закондагы 22 статьяның 1 өлешендә күздә тотылган очраклардан кала, эшләүченең эш ташлауда катнашуы хезмәт дисциплинасын бозу һәм хезмәт килешүен юкка чыгару нигезе итеп карала алмый.

Әлеге Законындагы 22 статьяның 1 өлешендә күздә тотылган очраклардан кала, эш ташлауда катнашкан эшләүчеләргә карата дисциплинар җәза чаралары куллану тыела.

Эш ташлау вакытында анда катнашучы хезмәткәрләрнең эш урыны һәм вазыйфасы саклана.

Эш бирүче эш ташлауда катнашу вакыты өчен хезмәткәрләргә, эшләрнең (хезмәт күрсәтүләрнең) мәҗбүри минимумын үтәү белән шөгыльләнүче хезмәткәрләрдән кала, хезмәт хакын түләмәскә хаклы.

Күмәк хезмәт бәхәсен хәл итү барышында ирешелгән күмәк шартнамә, килешү яисә килешүләр нигезендә эш ташлауда катнашучыларга компенсация түләүләре каралырга мөмкин.

Эш ташлауда катнашмаучы, әмма шул сәбәпле үз эшләрен башкара алмаган эшләүчеләргә хезмәт турындагы законнарда каралган тәртиптә һәм күләмдә хезмәт хакы түләнә. Эш бирүче бу эшләүчеләрне хезмәт турындагы законнарда каралган тәртиптә башка эшкә күчерергә хаклы.

19 статья. Локаутны (эштән кууны) тыю

Күмәк хезмәт бәхәсен җайга салганда, эш ташлау үткәрүне дә кертеп, локаут - күмәк хезмәт бәхәсеннән һәм эш ташлау турында игълан итүдән чыгып, эшләүчеләрне эш бирүче инициативасы белән эштән азат итү, шулай ук оешманы, аның филиалын, вәкиллеген ябу яисә үзгәртү тыела.

## IV бүлек
## Күмәк хезмәт бәхәсләре турындагы законнарны бозган өчен җаваплылык

**20 статья.** Килештерү процедураларында катнашудан читләшкән өчен җаваплылык

Эшләүчеләрнең таләпләрен кабул итүдән һәм килештерү процедураларында катнашудан баш тарткан, шул исәптән үз таләпләрен белдерү өчен эшләүчеләргә җыелыш (конференция) үткәрергә бина бирмәүче яисә аны үткәрүгә комачаулый торган эш бирүче дисциплинар җәзага тартыла яки аңа суд аша хезмәткә түләүнең илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

**21 статья.** Килешүне үтәмәгән өчен җаваплылык

Килештерү процедуралары аша ирешелгән килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәүдә гаепле эш бирүче вәкилләре дисциплинар җәзага тартыла яки аларга суд тәртибендә хезмәткә түләүнең илле минималь күләменә кадәр штраф салына.

**22 статья.** Законсыз эш ташлаулар өчен хезмәткәрләрнең җаваплылыгы

Эш ташлауны законсыз дип таныган яки аны кичектерү, туктатып тору турында үз көченә кергән суд карары эш ташлауга җитәкчелек итүче органга җиткерелүнең икенче көнендә, эш ташлауга керешкән яисә аны туктатмаган хезмәткәрләр хезмәт дисциплинасын бозган өчен хезмәт турындагы законнар нигезендә дисциплинар җәзага тартыла алалар.

Эш ташлау законсыз дип танылганнан соң, эш ташлауны игълан иткән һәм аны туктатмаган һөнәр берлекләре оешмасы законсыз эш ташлау аркасында күрелгән зыянны суд билгеләгән күләмдә үз акчалары исәбеннән капларга тиеш.

23 статья. Җаваплылыкка тарту тәртибе

Әлеге Законда күздә тотылган штрафларны салу турындагы эшләр административ хокук бозулар хакындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә карала.

24 статья. Кумәк хезмәт бәхәсен хәл иткәндә документларны алып бару

Кумәк хезмәт бәхәсен хәл итүгә бәйле рәвештә якларның гамәлләре, кабул ителә торган килешүләре һәм тәкъдимнәре якларның вәкилләре, килештерү органнары, эш ташлауга җитәкчелек итүче орган беркетмәләре белән рәсмиләштерелә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1998 елның 20 мае
№ 1599